**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3378**
**07.07.2022**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәткә карата 2022 елның 1 апреленә кадәр төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре нигезендә аренда түләвеннән азат итү рәвешендә ташлама билгеләү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәткә карата 2022 елның 1 апреленә кадәр төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре нигезендә аренда түләвеннән азат итү рәвешендә ташлама билгеләү турында» 2022 елның 13 апрелендәге 14/12 номерлы карары, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәткә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре, җир участокларына карата төзелгән муниципаль милектәге җир участокларын һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларын арендалау шартнамәләре нигезендә аренда түләвеннән азат итү рәвешендә ташлама билгеләү мәсьәләләре буенча комиссия төзү турында» 2020 елның 23 июнендәге 364-р номерлы боерыгы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәткә карата 2022 елның 1 апреленә кадәр төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре нигезендә аренда түләвеннән азат итү рәвешендә ташлама билгеләү тәртибе хакында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында (http://nabchelny.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 7 июлендәге
3378 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәткә карата
2022 елның 1 апреленә кадәр төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре
нигезендә аренда түләвеннән азат итү рәвешендә ташлама билгеләү
тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәткә карата 2022 елның 1 апреленә кадәр төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре нигезендә аренда түләвеннән азат итү рәвешендә «Профессиональ керемгә салым» махсус салым режимын куллана торган, арендага алынган торак булмаган бинада балаларның интеллектуаль, мәдәни, сәнгать-эстетик, спорт үсеше буенча һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы шәхси эшмәкәрләргә, оешмаларга, шәхси эшмәкәр булмаган физик затларга (алга таба арендатор) ташлама (алга таба- ташлама) бирү тәртибен билгели.

2. Ташлама муниципаль казна составында булган, муниципаль учреждениеләргә һәм муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә итү хокукында яки муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән һәм әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен бирелгән торак булмаган биналарга карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре (алга таба – аренда шартнамәсе) буенча аренда түләвеннән азат итү рәвешендә бирелә.

3. Ташлама аренда шартнамәсенең гамәлдә булу срогы чикләрендә 2022 елның 1 апреленнән 2023 елның 1 апреленә кадәр чорга әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы затларга аренда шартнамәсенә өстәмә килешү төзү юлы белән бирелә.

4. Арендаторның гаризасы ташлама бирү өчен нигез булып тора (нигезләмәгә 1 нче кушымта).

5. Арендага алынган торак булмаган бинада балаларның интеллектуаль, мәдәни, сәнгать-эстетик, спорт үсеше буенча эшчәнлекне тормышка ашыручы арендаторның гаризасына теркәлә:

1) яшь категориясе күрсәтелеп, торак булмаган бинаны баланста тотучы белән килештерелгән дәресләр расписаниесе;

2) гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

3) гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ күчермәсе.

6. Арендалана торган торак булмаган бинада җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы арендатор гаризасына теркәлә:

1) гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

2) гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ күчермәсе.

7. Ташлама бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) арендатор әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән шартларга туры килми;

2) арендатор тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында яки 6 пунктында каралган документлар тапшырылмау;

3) арендатор тарафыннан тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат булган документлар тапшырылу.

8. Арендатор шәхсән яки аның вәкаләтле заты электрон формада яисә кәгазьдә Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында яки 6 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп гариза бирә.

9. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе гаризаны терки һәм шул ук көнне карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

10. Башкарма комитет Җитәкчесе бер эш көне эчендә гаризаны, документларны карап тикшерә һәм Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә (алга таба – ҖММИ) җибәрә.

11. Әлеге Нигезләмәнең 7 пункты нигезендә ташламалар бирүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, гариза ҖММИгә кергән көннән башлап җиде эш көне эчендә ҖММИ гариза бирүчегә ташлама бирүдән баш тарту турында хат җибәрә.

12. Ташлама бирү өчен шартлар үтәлгәндә ҖММИ җиде эш көне эчендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәткә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре, җир участокларына карата төзелгән муниципаль милектәге җир участокларын һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларын арендалау шартнамәләре нигезендә аренда түләвеннән азат итү рәвешендә ташлама билгеләү мәсьәләләре буенча комиссия (алга таба – комиссия) утырышында гаризалар һәм документларны карап тикшерүне тәэмин итә.

13. Гариза һәм документлар комиссия тарафыннан карап тикшерелгән көннән башлап өч эш көне эчендә ҖММИ өстәмә килешү проектын (нигезләмәгә 2 нче һәм 3 нче кушымталар) әзерләүне гамәлгә ашыра һәм аны имзалау өчен арендаторга җибәрә.

14. Муниципаль казна составындагы торак булмаган биналарны арендалау шартнамәләре буенча арендатор өстәмә килешү проекты кергән көннән башлап дүрт эш көне эчендә әлеге проектны имзалау өчен ҖММИгә кире кайтара.

15. Муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә итү хокукында яки муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән һәм әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен бирелгән торак булмаган биналарга карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча:

1) арендатор өстәмә килешү проекты кергән вакыттан башлап ике эш көне эчендә әлеге проектны имзалый һәм имзалау өчен арендага бирүчегә җибәрә;

2) арендага бирүче өстәмә килешү проекты кергән вакыттан башлап ике эш көне эчендә әлеге проектны имзалый һәм имзалау өчен ҖММИгә җибәрә.

16. Өстәмә килешү проекты ҖММИгә кергән көннән башлап биш эш көне эчендә ҖММИ башлыгы өстәмә килешү проектын имзалый, ҖММИ белгече аны аренда шартнамәсенә өстәмә килешүләрне теркәү журналында терки.

Әгәр аренда шартнамәсе хокукларны теркәү органында теркәлгән булса, арендатор аренда шартнамәсе буенча өстәмә килешүне законда билгеләнгән тәртиптә теркәү органында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итә.

17. Арендага бирүче арендатор катнашында арендатор тарафыннан торак булмаган бинадан файдалануның әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән шартлары үтәлү предметына тикшерү үткәрергә һәм торак булмаган бинаны файдалануны тикшерү актлары (алга таба-акт) төзергә хокуклы (нигезләмәгә 4 нче кушымта). Тикшерү нәтиҗәләре буенча актның бер нөсхәсе арендаторга тапшырыла.

18. Арендатор тарафыннан әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән шартлар бозылганда, арендага бирүче акт төзи һәм аны бер эш көне эчендә ҖММИгә җибәрә.

19. ҖММИ акт кергән көннән башлап биш эш көне эчендә әлеге документны комиссия утырышында карап тикшерүне тәэмин итә. Актны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия ташламаны берьяклы тәртиптә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

20. Комиссия карары кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә ҖММИ арендаторга аренда шартнамәсенә өстәмә килешүнең берьяклы тәртиптә өзелүе турында хәбәр җибәрә (нигезләмәгә 5 нче кушымта).

21. Әлеге нигезләмә шартлары Башкарма комитетның 2020 елның 20 маендагы 2334, 2335 номерлы карарлары белән билгеләнгән аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләрне үтәүне кичектерүгә кагылмый.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе
Ф.Ш. Салаховка

2022 елның 1 апреленнән ____________________ чорга кадәр аренда
түләвеннән азат итү рәвешендә ташлама бирү турында
ГАРИЗА

_______________________________ (арендатор) ________________ һәм _________________________ (арендага бирүче) арасында 20___ елның «___» ____________ мәйданы__________кв.м. булган, _________________________________ _______________________________________________
(объектның адресы)
адресы буенча урнашкан бинаның ______ этажында торак булмаган бинага карата, _____________________________________
____________ (_______________________________________ ______) сум күләмендә айлык аренда түләве белән _____________номерлы муниципаль милекне арендалау шартнамәсе төзелде, ӨКСны исәпләмичә.

Хәзерге вакытта шартнамәнең гамәлдә булу срогы чыкмаган, шартнамә өзелмәгән.

Мөлкәтнең максатчан билгеләнеше ____________________________________.

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәткә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре нигезендә аренда түләвеннән азат итү рәвешендә ташлама билгеләү турында» 2022 елның 13 апрелендәге 14/12 номерлы карары нигезендә 2022 елның 1 апреленнән _________________ кадәр чорга аренда түләвеннән азат итүегезне сорыйм.

Әлеге мөрәҗәгатькә җавапны түбәндәге адрес буенча җибәрүегезне сорыйм: _____________________________________________________________________________.

Кушымта:

__________ __________
(дата) (имза)

Нигезләмәгә
2 нче кушымта

Аренда түләвеннән азат итү рәвешендә ташлама бирү турында
________елның _____________ ________номерлы муниципаль милекне арендалау шартнамәсенә ________елның _______________ _____ номерлы өстәмә килешү

__________ номерлы ышаныч кәгазе һәм нигезләмә нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән эш итүче Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллин исеменнән «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, алга таба - «арендага бирүче» дип аталучы, һәм «Арендатор» дип аталучы, _____________ нигезендә эш итүче _______________ исеменнән_______________________, бергә «Яклар» дип аталучылар, ________елның _____________ ________номерлы муниципаль милекне арендалау шартнамәсенә (алга таба - аренда шартнамәсе) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә карар кабул иттеләр:

1. Шәһәр Советының 2022 елның 13 апрелендәге 14/12 номерлы карары, комиссиянең _____елның _____________ ______номерлы беркетмәсе нигезендә Арендатор 2022 елның 1 апреленнән __________________________кадәр чор өчен аренда түләвеннән азат ителә.

Арендатор тарафыннан Шәһәр Советының 2022 елның 13 апрелендәге 14/12 номерлы карарында күрсәтелгән ташлама бирү шартлары бозылган очракта, Арендага бирүче, аренда шартнамәсенә өстәмә килешүне берьяклы тәртиптә өзү турында белдерү кәгазе җибәрү юлы белән, ташламаны берьяклы тәртиптә гамәлдән чыгара.

2. Әлеге өстәмә килешү аренда шартнамәсенең аерылгысыз өлеше булып тора. Калган өлешендә аренда шартнамәсе үзгәрешсез кала.

3. Әлеге өстәмә килешү Арендага бирүче һәм Арендатор өчен берәрдән бер үк юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелде.

4. Әлеге өстәмә килешү Яклар тарафыннан имзаланган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ______________елның _______________ _____номерлы аренда шартнамәсенең аерылгысыз өлеше булып тора.

4.[1] Әлеге өстәмә килешү Арендатор тарафыннан хокукларны теркәү органында дәүләт теркәве үткәрелгән вакыттан башлап үз көченә керә һәм __________елның _____________ ______номерлы аренда шартнамәсенең аерылгысыз өлеше булып тора.

## ЯКЛАРНЫҢ ИМЗАЛАРЫ:

| «Арендатор» | «Арендага бирүче» |
|---|---|
| ________________________________<br>телефон: ______________________<br>Адрес: _________________________<br>Р/счет ____________________________<br>Банк _____________________________<br>ИНН ____________, БИК ____________,<br>ОГРН ______________, КПП _________ | «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ<br>423805, Яр Чаллы шәһәре, Х.Туфан пр., 23 йорт |

[1] Шартнамә бер ел һәм аннан күбрәк срокка төзелгән очракта кертелә.

| | |
|---|---|
| Җитәкче | Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы |
| ____________________ ________________ | |
| имза м.у. | _______________________Л.Р. Гыйззәтуллин |
| | м.у. |

Нигезләмәгә
3 нче кушымта

Аренда түләвеннән азат итү рәвешендә ташлама бирү турында
________елның _____________ ________номерлы муниципаль милекне арендалау шартнамәсенә ________елның ______________ _____ номерлы өстәмә килешү

__________ номерлы ышаныч кәгазе һәм нигезләмә нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән эш итүче Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллин исеменнән «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, алга таба - «Милекче» дип аталучы, «Арендага бирүче» дип аталучы, Устав һәм_____________ нигезендә эш итүче _______________ исеменнән________________________ һәм «Арендатор» дип аталучы, _____________ нигезендә эш итүче _______________ исеменнән_______________________, бергә «Яклар» дип аталучылар, ________елның _____________ ________номерлы муниципаль милекне арендалау шартнамәсенә (алга таба - аренда шартнамәсе) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә карар кабул иттеләр:

1. Шәһәр Советының 2022 елның 13 апрелендәге 14/12 номерлы карары, комиссиянең _____елның _____________ ______номерлы беркетмәсе нигезендә Арендатор 2022 елның 1 апреленнән _____________ кадәр аренда түләвеннән азат ителә.

Арендатор тарафыннан Шәһәр Советының 2022 елның 13 апрелендәге 14/12 номерлы карарында күрсәтелгән ташлама бирү шартлары бозылган очракта, Милекче, аренда шартнамәсенә өстәмә килешүне берьяклы тәртиптә өзү турында белдерү кәгазе җибәрү юлы белән, ташламаны берьяклы тәртиптә гамәлдән чыгара.

2. Әлеге өстәмә килешү аренда шартнамәсенең аерылгысыз өлеше булып тора. Калган өлешендә аренда шартнамәсе үзгәрешсез кала.

3. Әлеге өстәмә килешү Милекче, Арендага бирүче һәм Арендатор өчен берәрдән бер үк юридик көчкә ия өч нөсхәдә төзелде.

4. Әлеге өстәмә килешү Яклар тарафыннан имзаланган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ______________елның _______________ _____номерлы аренда шартнамәсенең аерылгысыз өлеше булып тора.

4.[2] Әлеге өстәмә килешү Арендатор тарафыннан хокукларны теркәү органында дәүләт теркәве үткәрелгән вакыттан башлап үз көченә керә һәм __________елның _____________ ______номерлы аренда шартнамәсенең аерылгысыз өлеше булып тора.

## ЯКЛАРНЫҢ ИМЗАЛАРЫ:

| «Арендатор» | «Арендага бирүче» |
|---|---|
| ________________________________ | ________________________________ |
| телефон: ______________________ | телефон: ______________________ |
| Адрес: _________________________ | Адрес: _________________________ |
| Р/счет _____________________________ | Р/счет _____________________________ |
| Банк _______________________________ | Банк _______________________________ |
| ИНН ____________, БИК ____________, | ИНН ____________, БИК ____________, |
| ОГРН ______________, КПП _________ | ОГРН ______________, КПП _________ |
| Җитәкче | Җитәкче |
| ___________________ _______________ | м.у. |
| имза м.у. | |

[2] Шартнамә бер ел һәм аннан күбрәк срокка төзелгән очракта кертелә.

«Милекче»
«Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты» МКУ
423805, Яр Чаллы шәһәре, Х.Туфан пр., 23 йорт
Башкарма комитетның җир һәм
мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы

________________________Л.Р. Гыйззәтуллин
м.у.

Нигезләмәгә
4 нче кушымта

202___ елның «_____» ______________ _________номерлы
торак булмаган бинадан файдалануны тикшерү
АКТЫ

______________________________________________________________________________
(арендага бирүченең вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)

Башкарма комитетның 2022 елның «____» ___________карары нигезендә,
________________________________________________________________
(арендага бирүченең чакырылган вәкиленең вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)
җәлеп итеп, _________________________________________________________________
(арендаторның вазыйфасы, фамилия, инициаллары)
______________________________________________________________________________
(тикшерүдә катнашкан башка затларның вазыйфасы, фамилияләре, инициаллары, шәхесен таныклаучы документ реквизитлары)

катнашында ________________________________________________
(торак булмаган бинаның исеме)
файдалануны тикшерде, адресы:
____________________________________________________

Торак булмаган бинадан файдалануны тикшерү барышында билгеләнде:
______________________________________________________________________________

Тикшерү барышында ачыкланган кимчелекләр:
________________________________________

Акт торак булмаган бинаны фактта тикшергәндә алынган мәгълүмат, шулай ук тапшырылган документларны анализлау нигезендә төзелде.

Актка теркәлә:____________________________________________________________
(актка теркәлүче документларны күрсәтергә)

Тикшерү үткәргәндә катнашкан затларның имзалары:

_________________________________ ____________________
(тикшерүченең вазыйфасы, имзасы) (И.А.и. Фамилия)

_________________________________ ____________________
(арендага бирүче вәкиленең вазыйфасы, имзасы) (И.А.и. Фамилия)

_________________________________ ____________________
(арендаторның вазыйфасы, имзасы) (И.А.и. Фамилия)

_________________________________ ____________________
(тикшерүдә катнашкан башка затларның вазыйфасы) (И.А.и., фамилия)

Актның икенче нөсхәсен алдым: ______________________________________________
(арендаторның вазыйфасы,фамилиясе, инициаллары, дата, имзасы)

Нигезләмәгә
5 нче кушымта

Арендаторга ____________

_______________________________ ______номерлы аренда шартнамәсенә
_________________________ ____номерлы Өстәмә килешүне берьяклы тәртиптә өзү турында белдерү кәгазе

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе (Арендага бирүче) һәм _________________________ (Арендатор) тарафыннан _______________ ______номерлы аренда шартнамәсенә Өстәмә килешү төзелде (алга таба – Өстәмә килешү).

Өстәмә килешү шартлары нигезендә Яклар ________________ _____номерлы муниципаль милекне арендалау шартнамәсенә Арендаторны 2022 елның 1 апреленнән ___________кадәр чор өчен аренда түләвеннән азат итү өлешендә үзгәрешләр керттеләр.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәткә карата 2022 елның 1 апреленә кадәр төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре нигезендә аренда түләвеннән азат итү рәвешендә ташлама билгеләү тәртибе хакында нигезләмәнең 18 – 20 пунктлары нигезендә, арендатор тарафыннан ташламалар бирү шартлары бозылган очракта, арендаторга аренда шартнамәсенә Өстәмә килешүнең берьяклы өзелүе турында хәбәр җибәрү юлы белән ташлама гамәлдән чыгарыла.

_____________ тикшерү акты белән ташлама бирү шартларының бозылуы ачыкланды.

Арендатор Шәһәр Советының 2022 елның 13 апрелендәге 14/12 номерлы карары белән билгеләнгән ташлама бирү шартларын бозган. Комиссиянең ___________________ ____номерлы утырышында ташлама бирүдән баш тарту турында карар кабул ителде.

Моның белән Сезгә хәбәр итәбез, __________________ ______номерлы Өстәмә килешү әлеге белдерү кәгазен алган көннән өзелгән дип санала.

Башкарма комитетның
җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр
идарәсе башлыгы ______________________